**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЯҢА ЧИШМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-20-08, факс: (8-84348) 2-21-73, Nsmsp.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

29 нчы июнь 2022 ел № 20-73

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы 2019 елның 14 нче ноябреннән 79-129 нчы номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә» үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 15 ноябрендә 50-166 номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеге советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә» (31.05.2021 №10-32; 05.10.2021 №13-49 от 14.12.2021 №16-58 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 «Бюджет процессы принциплары» статьясына түбәндәге эчтәлекле яңа унынчы абзац өстәргә:

«- гражданнарның бюджет процессында катнашуы;»;

унынчы - унөченче абзацларны унберенче - ундүртенче абзацлар дип санарга;

1.2. «Җирлекнең муниципаль бурычы структурасы» 16 статьясындагы 23 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) максатчан чит ил кредитларыннан файдалану кысаларында Җирлек тарафыннан бирелгән чит ил валютасында муниципаль гарантияләрдән чыга торган йөкләмәләр күләме;»; (РФ БК 100 маддәсе буенча)

1.3. «Муниципаль алынмаларның чик күләме» 20 статьяның 2 өлешендә «Поселениенең бурыч йөкләмәләре,» сүзләреннән соң «инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә җәлеп ителгән бюджет кредитының тиешле ел ахырына файдаланылмаган калдыгы күләменнән тыш,» сүзләрен өстәргә;

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы”нда әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә - http//pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының “Интернет” мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) http/ novosheshminsk.tatarstan.ru/.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Яңа Чишмә авыл җирлеге башлыгы В.М.Козлов